РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Масягутовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ул. Дружба, д. 12, Азнакаевский район, с.Масягутово, 423321,
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге
башлыгы

Дружба ур., 12 йорт, Азнакай районы, Мәсгут авылы, 423321
тел./факс (885592)38-2-16
E-mail: Msg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

**от «08» ноября 2022г.**

**№ 5**

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 18 ноябренә 16.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауларны расларга:

«Сез, 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 250 сум күләмендә

билгеләп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай авылында зират коймасын алыштыру (монтажлау, панель алу);;

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай авылы мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык: Д.З. Миннеханов